МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ
ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ
И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ
ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ
ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

22.05.2026 № 124

**Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының 09.01.2014 № 6 боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгында биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлегенә үзгәреш кертү турында**

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының штат расписаниесе үзгәрүгә бәйле рәвештә, шулай ук дәүләт граждан хезмәте турындагы законнарны гамәлгә ашыру максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының (алда - Татарстан Республикасы ГТХМ) 09.01.2014 № 6 боерыгы белән расланган (05.05.2014 № 205, 14.12.2015 № 572, 23.05.2016 № 215, 09.04.2019 № 136, 25.06.2020 № 209, 04.08.2021 № 256, 17.11.2021 № 388, 13.10.2022 № 300, 27.10.2022 № 310, 27.12.2023 № 365, 05.03.2024 № 72, 09.04.2026 № 79 Татарстан Республикасы ГТХМ боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгында биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм

балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлегенә алдагы үзгәрешне кертергә:

I бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I. «Җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категорияле дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары (2006 ел, 18 нче гыйнвар № УП-9 Татарстан Республикасы Президенты Указы белән расланган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Реестры нигезендә):

Министрның беренче урынбасары;

Министр урынбасарлары;

Эшләр белән идарә итүче;

Финанс-икътисад идарәсе башлыгы;

Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү бүлеге башлыгы;

Геомәгълүмат системалары бүлеге башлыгы;

Территориаль хезмәттәшлек һәм реабилитация бүлеге башлыгы;

Перспектив үсеш бүлеге башлыгы;

Гражданнар оборонасы өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру бүлеге башлыгы;

Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлеге башлыгы;

Эшчәнлекне планлаштыру бүлеге башлыгы;

Мәгълүмат бүлеге башлыгы;

Мәгълүмат коммуникацияләре технологияләре һәм мәгълүматны саклау бүлеге башлыгы;

Хәбәр итү һәм элемтә бүлеге башлыгы;

Хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы;

Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге башлыгы;

Вазыйфаи затларны һәм халыкны әзерләү бүлеге башлыгы;

Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлеге башлыгы;

Авария-коткару формированиеләрен төзү, аттестацияләү һәм теркәү бүлеге башлыгы;

Оештыру эше бүлеге башлыгы;

Кризиска каршы идарә секторы мөдире;

Мобилизация эше секторы мөдире;

Эшчәнлекне планлаштыру бүлеге башлыгы урынбасары.».

2. Әлеге боерыкны Татарстан Республикасы ГТХМ аппаратының министр урынбасарларына, структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм дәүләт граждан хезмәткәрләренә җиткерергә.

Министр вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А. Н. Орлов